ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutazaik@mail.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**« 06 » 12 2023г.** **№2002**

Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 659/1 номерлы карары белән расланган, 2019-2023 елларга Ютазы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 659/1 номерлы карары белән расланган, 2019-2023 елларга Ютазы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Муниципаль программаның 5 бүлегенең 1 абзацы «30 елга кадәр» сүзләрен «35 елга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Муниципаль программаның 1 нче кушымтасының 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү | ЮМР БКның территориаль үсеш бүлеге, ЮМР БКның муниципаль заказ буенча секторы | 2019-2023 еллар | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу | | | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Сучкова А.В.
8(85593)2-80-12